ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.12.2024 ел Баулы шәһәре №195

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 30 июлендәге 116 номерлы карары белән расланган (2022 елның 13 маендагы 82 номерлы, 2024 елның 11 ноябрендәге 163 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән), индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты объектының планлаштырыла торган төзелеше турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыру мөмкинлеге турында хәбәрнамә юлламасы буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Министрлыгының 2024 елның 18 октябрендәге 1-31/15348 номерлы хаты нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 30 июлендәге 116 номерлы карары белән расланган (2022 елның 13 маендагы 82 номерлы, 2024 елның 11 ноябрендәге 163 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән), индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты объектының планлаштырыла торган төзелеше турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыру мөмкинлеге турында хәбәрнамә юлламасы буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3 «Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары, аларны башкару тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны башкару үзенчәлекләре. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең

гомуми билгеләр белән берләштерелгән мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә, шул исәптән алар сорап мөрәҗәгать иткән муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә карата күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтү тәртибен үз эченә алган вариантлары» бүлегендә:

«әлеге административ регламентның 3.3.3.1 пунктында күрсәтелгән аерым процедураларны үтәү кысаларында һәм шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле булганнарның пространство белешмәләренең милли системасы эшләвен тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.»;

3.4.4. пунктын түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«әлеге административ регламентның 3.4.1., 3.4.3. пунктларында күрсәтелгән аерым процедураларны үтәү кысаларында, һәм шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле булганнарның пространство белешмәләренең милли системасы эшләвен тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.»;

3.5.4. пунктын түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«әлеге административ регламентның 3.5.2., 3.5.3. пунктларында күрсәтелгән аерым процедураларны үтәү кысаларында һәм шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле булганнарның пространство белешмәләренең милли системасы эшләвен тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.»;

3.6.1. пунктын түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле аерым процедураларны үтәү кысаларында пространство белешмәләренең милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы (http://www.bavly.tatarstan.ru) сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров